**СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422728, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Мемдель, ул.Кооперативная, д. 30

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422728, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Мәмдәл авылы, Кооператив ур, 30

Тел./факс: +7(84365) 60-2-37, e-mail: Memdel.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**9 июня 2020г.** **№ 170**

**Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2019елның 2 апрелендәге 132 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарын гамәлдән чыгару турында**

2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 48 статьясының 1 өлешенә, «Мәмдәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Гамәлдән чыгарырга:

Мәмдәл авыл җирлеге Советының 2019 елның 2 апрелендәге 132 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарын.

2. Әлеге карарны Мәмдәл авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Ф.Г.Сафиуллин